ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 20.11.2020 г. Казань № 243-76/кс-2020

2021 елга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен салкын суны транспортлаганга һәм агынты суларны транспортлаганга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен салкын суны транспортлаганга һәм агынты суларны транспортлаганга шушы карар кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.11.2020 № 183-40/кс-2020
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен салкын суны транспортлаганга һәм агынты суларны транспортлаганга 2021 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Салкын суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | |
| | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Түбән Кама гидроэлектростанциясе» (тарифлар НДС башка күрсәтелде) | | | 1,30 | 1,41 |
| 1.2 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Чаллы ҖЭҮ» (тарифлар НДС башка күрсәтелде) | 0,77 | 0,77 | 0,87 | 0,87 |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | |
| 1.3 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Казан җылылык электр үзәге-1» (тарифлар НДС башка күрсәтелде) | 0,14 | 0,31 | 0,24 | 0,24 |
| 1.4 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Казан җылылык электр үзәге-2» (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелде) | 0,19 | 0,19 | 1,51 | 1,51 |
| 1.5 | «Татэнерго акционерлык җәмгыяте филиалы – «Балкыш» санаторий-профилакторие (тарифлар НДС башка күрсәтелде) | | | 8,23 | 8,23 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге